Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәренең Яшь натуралистлар урамы буенча торак йортлар территориясе өлешендә 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

26 декабрь 2022 ел №1

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре территориясе өлешендә гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Зеленодольск шәһәре Яшь натуралистлар урамы буенча торак йортлар территориясе өлешендә гражданнарның яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 4000 (дүрт мең) сум күләмендә үзара салым кертергә
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яшь натуралистлар урамының сууткәргечен алыштыруга;
- Яшь натуралистлар урамы территориясен төзекләндерүгә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ____________ / ____________

Зеленодольск шәһәре Хакиме М.П.Афанасьев